УПРАВЛЕНИЕ
ПО ОХРАНЕ И ИСПОЛЬЗОВАНИЮ ОБЪЕКТОВ ЖИВОТНОГО МИРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ ҺӘМ АЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ

**Приказ** **Боерык**

18.10.2016 г. Казань № 212-од

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең 19.08.2014 елдан 112-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт граждан-лык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турындагы Кагыйдәнамәгә үзгәрешләр кертү турында

2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канун белән тәңгәл килеп **б о е р а м :**

1. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең 19.08.2014 елдан 112-од номерлы “Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турындагы Кагыйдәнамәне раслау турында” (алга таба – Кагыйдәнамә) боерыгы белән расланган, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турындагы Кагыйдәнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче Кушымтага:

2 нче пунктны киләсе басмада бирергә:

“2. Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынына куела торган Квалификация таләпләренә туры килмәү белән, ә шулай ук гражданлык хезмәтенә керүгә һәм анда хезмәт итүгә Россия Федерациясе кануннары белән урнаштырылган дәүләт гражданлык хезмәте турындагы чикләүләр белән бәйле рәвештә,гражданин Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) Бәйгедә катнашуга кертелми.”;

3 нче пунктны киләсе басмада бирергә:

“3. Белемгә һәм гражданлык хезмәтенең стажына яки эш стажына квалификация таләпләре.

Гражданлык хезмәте вазифаларына куелган квалификация таләпләре санына, “җитәкчеләр”, “булышчылар(киңәшчеләр), гражданлык хезмәтендәге төп һәм өлкән “белгечләр” дәрәҗәләренә белгечтән дә ким булмаган югары белем, магистратура кирә.

Гражданлык хезмәте вазифаларына куелган квалификация таләпләре санына, “җитәкчеләр”, “булышчылар(киңәшчеләр), гражданлык хезмәтендәге төп һәм өлкән “белгечләр” дәрәҗәләренә, ә шулай ук гражданлык хезмәтенең баш һәм алдан баручы төркемнәрен “тәэмин итүче белгечләр” категориясенә югары белемле булу кирә.

Гражданлык хезмәте вазифаларына куелган таләпләрнең санына, гражданлык хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрен “тәэмин итүче белгечләр” категориясенә, эш юнәлешенә туры килүче урта профессиональ белемле булу кирә.

Гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, гражданлык хезмәткәрләре өчен әзерлек юнәлеше буенча түбәндәге квалификация таләпләре куела:

баш төркемнең бөтен категорияләрендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен – алдынгы яки өлкән төркем гражданлык хезмәте вазифаларында ике елдан да ким булмаган гражданлык хезмәте стажы, яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча 3 елдан да ким булмаган эш стажы;

алдынгы төркемнең бөтен категорияләрендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен – бер елдан да ким булмаган өлкән яки кече төркем гражданлык хезмәте вазифаларында гражданлык хезмәте стажы, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча яки ике елдан да ким булмаган эш стажы;

өлкән яки кече төркем гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен гражданлык хезмәте стажына (тәҗрибәсенә), яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре куелмый.

Гражданлык хезмәте стажын билгеләгәндә, шулай ук аның санына федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең туры килгән вазифа төркемнәре һәм аларга тиңләнгән хәрби һәм хокук саклау хезмәтләре, ә шулай ук муниципаль хезмәт вазифасының туры килгән төркемнәре кертелә.”;

Кагыйдәмәнең 2нче Кушымтасындагы 1 пунктның 5 нче кече пунктын төшереп калдырырга.

2. Боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырырга.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков